Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №LII-3**

Балык Бистәсе штп. 13 март, 2020 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2009 елның 27 июлендәге XXXX-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, 2019 елның 16 декабрендәге “Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында” 439-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2009 елның 27 июлендәге XXXX-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2009 елның 24 сентябрендәге XLV-8 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2.5 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) хезмәт кенәгәсен һәм ( яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны, хезмәт шартнамәсе (контракт) тәүге тапкыр төзелгән очраклардан гайре;”.

1.2. 7.3 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5) хезмәт кенәгәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларның, яисә хәрби яки бүтән хезмәттә булуны раслый торган документ күчермәсе;”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы
вазифаларын башкаручы Ф.Г.Әхмәтҗанова